“Нуркайлар” 131нче балаларның танып белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

“КИЛЕШЕНДЕ”
“Нуркайлар”131 нче балалар бакчасы
МБМББУ өлкән тәрбиячесе
______________Шарафутдинова Э.Н.
«_29_» _____08_____________2022 ел

“РАСЛАНДЫ”
“Нуркайлар” 131 нче балалар бакчасы
МБМББУ мөдире
_____________________Литвинцева Л.С.
« _29_ »____08__________ 2022 ел

Каралды һәм кабул ителде
педагогик советта
Протокол № 1
«_29_» _____08_____________2022 ел

12 нче (3-4 яшь) санлы икенче кечкенәләр төркеменең
2022-2023 нче уку елына
гомумүстерешле белем бирү юнәлешендә
белем бирү эшчәнлегендә
эш программасы.

Программа авторы:
Габдрахманова Рузилә Ринат кызы
Сибгатуллина Алина Ришат кызы

Яр Чаллы шәһәре
2022 ел

*Эчтәлек*

1. Аңлатма язуы.
2. Тәрбия бурычлары.
3. Төркемдә тәрбияләнүче балалар турында белешмә.
4.  Көндәлек режим.
5.  Психологик- педагогик эшнең эчтәлеге.

6.1Сәламәтлек.
6.2 Танып белү.Иң гади математик күзаллауларын  үстерү.
6.3Аралашу.Сөйләм телен үстерү.
6.4 Танып белү.Әйләнә тирә белән танышу.
6.5 Социальләштерү.
6.6  конструкцияләү.
6.7 Сынлы сәнгать эшчәнлеге.Рәсем.
6.8 Сынлы сәнгать эшчәнлеге.Әвәләү.
6.9 Сынлы сәнгать эшчәнлеге.Кисеп ябыштыру.

7. Тормыш иминлеге саклау.
8. Әти- әниләр белән эш.
9. Программа үтәлешен йомгаклау нәтиҗәләре.
10. Икенче кечкенәләр төкемендә милли төбәк компоненты куллану.
11. Кулланылган әдәбият.

***Аңлатма язуы***

Әлеге программа Н.Е.Вераксы, Т.С. Комарова, М. А. Васильевалар тарафыннан төзелгән “Туганнан алып мәктәпкәчә” программасына таянып төзелгән.

Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше көннән- көн яңара, матур традицияләргә байый. Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шахси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә.

Балалар бакчаларының эшен камилләштерү һәм эчтәлеген яңарту буенча үзгәрешләр кертелгән бу программа, мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре алдында түбәндәге бурычларны куя:

- Балаларның сәламәтлеген саклау, аларның физик һәм психик үсешен тәэмин итү;
- Тәрбия – белем бирү эшен гуманлаштыру;
- Халык традицияләренә милли гореф гадәтләргә нигезләнеп балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү;
- Балаларның сәләтләрен ачу, юнәлеш бирү һәм үстерү өчен шартлар тудырып, нык белемле, зирәк акыллы шәхес формалаштыру.

Әлеге бурычларга ирешү эшчәнлекнең төрле вакытларында алып барыла:

- Белем бирү эшчәнлеге( уен, аралашу, хезмәт, музыкаль, уку)
- Балаларның көндәлек эшчәнлеге;
- Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;
- Программаны тормышка ашыру максатыннан ата -аналар белән даими эш.

Программа тарафыннан кулланган бурычларны тормышка ашыру белем бирү эшчәнлеге вакытында гына түгел, ә әлеге балалар бакчасы эчендәге үзенчәлекләргә таянып төзелгән көндәлек эшчәнлек вакытында да алып барыла.

Эш программасның эчтәлеге – физик, социаль, танып белү, аралашу, сынлы сәнгать юнәлешләре буенча, шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен күздә тотып, балага тәрбия һәм белем бирүдә юнәлтелгән эшчәнлек төрләрен үз эченә ала.

***Тәрбия бурычлары***

Организмнарын даими рәвештә чыныктыру, занятияләрдә, шулай ук башка вакытта төп хәрәкәт төрләрен башкару осталыкларын һәм күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү, матур гәүдә, шулай ук гигиена күнекмәләре тәрбияләү өчен шартлар тудырып, балаларның сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклануын дәвам иттерү;көндәлек режимны төгәл үтәү. Балаларның пространствода ориентлаша белүләрен камилләштерү. Күмәк уеннарда һәм физик күнекмәләрдә катнашуга дәртләндерү.

Мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлекләрендә уңай эмоцияләр, активлык формалаштыруга булышлык итү.

Әйләнә-тирәсендәге кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеге, табигать күренешләре белеп кызыксыну, тирә-юнендәге предметлар һәм күренешләргә игьтибар туплый белүне тәрбияләү.

Предметлар һәм күренешләр арасындагы бәйләнешләрне аңларга һәм шуның аша гади генә нәтиҗәләр чыгарырга белергә өйрәтү.

Өлкәннәр хезмәтенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру.Көченнән килгән кадәр хезмәткә катнашу теләген уяту,кечерәк кыенлыкларны җиңә белергә өйрәтү.
Балаларның дөрес сөйләмнәренә: сүзлек составларын баетуга,җөмләләрне төзи белүләренә,сүзләрне дөрес һәм ачык итеп әйтүләренә ирешү.
Әдәби әсәрен азаккача тыңлый,әсәрләрдәдә вакыйгаларның ничек үрелеп баруын күзәтә белү сыфаты тәрбияләү.
Балаларның музыкаль сәләтләрен устерү, музыканың яңгырашындагы үзгәрешләрне тоя белергә өйрәтү.

Балалар бакчасында, өйдә, урамда,бердәм тәртип күнекмәләрен ныгыту.
Нәрсә яхшы һәм нәрсә начар булуы турында иң гади кузаллау формалаштыруны дәвам иттерү.
Балаларда әйләнә-тирәнең матурлыгына, сәнгать әсәрләренә эстетик караш тәрбияләү.
Кыска шигырьләрнең,шаян сүзләрнең мәгънәсен аңлап сөйләргә, тормыштагы катлаулы булмаган предмет һәм вакыйгаларны рәсемдә,әвәләп сүрәтләр ясауда чыгылдыра белергә өйрәтү,җырның һәм музыкага туры килгән ритмик хәрәкәтләрнең тәэсирен аңлар дәрәҗәгә китереп җиткерү.

## ***КӨНДӘЛЕК РЕЖИМ***
### ***икенче кечкенәләр төркеме***
### **(2022-2023 нче уку елы)**

| **№** | **Режим моментлары** | **Вакыты** |
|---|---|---|
| 1 | Балаларны каршы алу, кабул итү. Уеннар, балаларның тәрбияче белән бергә эшчәнлеге | 7.00-7.30 |
| 2 | Иртәнге гимнастикага әзерлек, иртәнге гимнастика | 7.30-7.45 |
| 3 | Гигиеник процедуралар, иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш | 7.45-8.20 |
| 4 | Гигиеник процедуралар, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, белем бирү эшчәнлегенә әзерлек. | 8.20-9.00 |
| 5 | Белем бирү эшчәнлеге, бүлмәне җилләтү (10 минут) | 1. 9.00-9.15<br>2. 9.30-9.45 |
| 6 | Саф Һавада йөрергә әзерләнү | 10.15-10.20 |
| 7 | Саф Һавада йөрү | 10.20-11.15 |
| 8 | Урамнан керү, гигиеник процедуралары, уеннар, көндезге ашка әзерлек | 11.15-11.30 |
| 9 | Көндезге ашка әзерлек, көндезге аш | 11.30-12.00 |
| 10 | Гигиеник процедура. Йокыга әзерләнү | 12.00-15.00 |
| 11 | Йокыдан тору, сәламәтлекне ныгыту чаралары, Һава-су процедуралары | 15.00-15.15 |
| 12 | Төшке ашка әзерләнү, төшке аш | 15.15-15.25 |
| 13 | Шәхси эш, белем бирү эшчәнлеге, уеннар, нәфис әдәбият уку, балаларның тәрбияче белән яисә мөстәкыйль эшчәнлеге Балаларны өйгә озату. | 15.25-16.00 |

***Турыдан- туры белем бирү эшчәнлеге***

| **Эшчәнлекнең төре** | **Күләме** |
|---|---|
| Физик тәрбия | Атнага 3 тапкыр |
| Танып белү<br>Әйләнә-тирә белән танышу | Атнага 1 тапкыр |
| Аралашу<br>Сөйләм үстерү | Атнага 1 тапкыр |
| Сынлы сәнгать<br>Рәсем<br>Әвәләү<br>Кисеп ябыштыру/ Конструкцияләү | <br>Атнага 1 тапкыр<br>Атнага 1 тапкыр<br>Атнага 1тапкыр |
| Музыка | Атнага 2 тапкыр |

***Психологик- педагогик эшнең эчтәлеге***

Максат: балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту; сәламәт яшәү рәвеше нигезләре белән таныштыру. Сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллау булдыру.

| ***Ай*** | ***Физик эчшәнлеге*** | ***Культура гигиена күнекмәләре тәрбияләү*** | ***Сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллау булдыру*** |
|---|---|---|---|
| сентябрь | Медицина хезмәткәрләре күзәтчелегендә, һава, кояш, судан файдаланып, чыныктыру чаралары комплексы уздыру. | Балаларны пөхтәлеккә, тышкы кыяфәтен тәртиптә тотарга күнектерү. | Диагностика.<br>Әңгәмә " Кеше әгъзалары" 12б.(3)Шигырь " Утыр балам ашарга" 55б.(4)<br>"Чыныктыру" әти әниләр өчен мәгълумат. |
| октябрь | Бина эчендә җиңел киенеп йөрергә күнектерү.<br>Көндәлек режимга ярашлы рәвештә саф һавада йөрү. | Кул битне мөстәкыйль рәвештә чиста итеп юарга, сабын, тарактан дөрес файдаланырга, юынганнан соң сөртенергә, сөлгене урынына элеп куярга.<br><br>Кирәк булганда кулъяулыктан файдаланырга, тешләрне чистартыра гәдәтәндерү. | Әңгәмә " Шәхси гигиена әйберләрен дөрес куллану" 64б.(5)<br>Уен "Ашамлыкны дөрес әйт"13б.(6)<br>Рәсемнәр буенча сөйләшү" Көн тәртибе"<br>Шигырь" Беренче рәхмәт"55б.(4) |
| ноябрь | Һәр көнне 5-6 минутлык иртәнге гимнастика үткәрү.<br>Һавада йөргәндә хәрәкәтле күмәк уеннарда һәм физик күнегүләрдә катнашырга, шөгыльләрдән тыш вакытларда физкультура җиһазларыннан файдаланырга өйрәтү | Ашау күнекмәләре формалаштыру: ипине вакламаска, азыкны түкми- чәчми ашарга, ашаганда авызны чәпелдәтмәскә, кашык, чәнечке, салфеткадан дөрес файдаланырга күнектерү. | Әңгәмә " Киенү һәм чишенү әдәбе" 65б. (5)<br>Уен "Күрсәт әле үскәнем"329б.(7)<br>Әти-әниләр өчен мәгълумат "Куркынычсызлыкны ничек булдырмаска"<br>Табышмаклар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| декабрь | Чаңгыда йөрергә, таудан чана шуарга, өч тәгәрмәчле | Ризык капкан килеш сөйләшү, ашаганда аякларын селкеп утыруның тәрбиясезлек икәнлеген төшендерү. | Рәсемнәр буенча әңгәмә "Гөмбәләр"<br>Уен " Иртәнге күнегүләр"277б.(7)<br>С/р уен " Аюны табибка алып барабыз"<br>Әти-әниләр өчен мәгълумат "Йогышлы авырулар"<br>Әңгәмә " Юына белү"66б.(5) |
| январь | Айга 1 мәртәбә,15-20 минутлык хәрәкәтле ял вакыты( физкультурный досуг) оештыру. | Өстәл янында үз-үзенне тоту кагыйдәләрен искә төшерү. Өс киемнәрен чиста итеп тотарга күнектерү. | Рәсемнәр буенча әңгәмә " Минем өем"<br>Уен " Алсу нинди кием киеп йөри"440б.(7)<br>Д/у " Тапкып җәяүле"21б.(8)<br>Табышмаклар.<br>Шигырь " Юынырга кил мәче"11б.(9)<br>Әңгәмә " Табын янында матур утыру әдәбе"68б.(6) |
| Февраль | Физик күнегүләр белән кызыксынуны тәрбияләү. | Һәрвакыт чәчләрне тарап, кызларга үреп йөрергә кирәклеген аңлату. | Шигырь" Ул шуңа кеченә"60б.(4),"<br>Тәти кул"61б.(4)<br>Уен"Сүзләр чылбыры"259б.(7)<br>Әти-әниләр өчен консультация |
| Март | Саф һавада уеннар оештыру. | Урамнан,прогулкалардан кергәч һәрвакыт кулларны юарга кирәклкген аңлату. | Әңгәмә " Табиб безнең турыда кайгыртучы"73б.(5)<br>Уен " Яшелчәләр"262б.(7) Рәсемнәр буенча әңгәмә " Җиләелер"<br>Уен " Курчакны чишендерү"20б.(6)<br>Шигырь "Гөлсөя"91б.(4) |
| Апрель | Хәрәкәтле уеннар оештыру. Уеннарда актив катнашу теләге булдыру. | Урамда йөргәндә өс киемнәрен пычратмый гына йөрүләренә ирешү. Бүлмәдә һәрвакыт чисталык булдыру. Тузаннарны сөртеп чыгу күнекмәләрен бирү. | Әти-әниләр өчен мәгълумат " Гигиена кагыйдәләре"<br>Әңгәмә " Сәламәтлек-зур байлык"50б.(6)<br>Шигырь " Алсу"76б.(9)<br>Уен " Ни өчен кирәк"49б.(9)<br>Әти-әниләр өчен консультация" Өйдә Һава чистамы?" |

***Социальләштерү***

Максат: Социаль- иҗтимагый тәрбия турында беренче күзаллауны үзләштерү.

- Балаларда төрре уеннар белән төрле кызыксынучанлык тәрбияләү.
- Бер-берсе белән уртак тел табуларыны ирешү.

| ***Ай*** | ***Сюжетлы-рольле уеннар***<br>***Хәрәкәтле уеннар***<br>***Дидактик уеннар***<br>***Сәхнәләштерелгән уеннар*** | ***Балаларны бер-берсе белән уртак тел табарга җылы мөнәсәбәттә була белергә өйрәтү.*** | ***Гаилә әгъзалары арасында булырга тиеш гомумкешелек кыйммәтләренең өстенлеге турында күзаллау булдыру.*** |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | Диагностика<br>*С/р уен* “Гаилә”,”Шифаханә”<br>*Д/уен* “Бу рәсемдә нинди төсләр кулланылган?”(7),”Уенчыкны тап” (10),”Бу кемнең баласы?”(7),”Җиләк-җимешләр”(7),”Бу хайван ничек кычкыры?”(7)<br>*Х/уен* ”Күрсәт әле үскәнем”(10),тат халык уены “ Без,без,без идек...”(6),”Песи һәм тычканнар”(10),”Мин куам син кач”(10).<br>*Сәхнәл.уен* “Йомры икмәк.” | Диагностика<br>“Болай ярый,болай ярамый” 92б.(11)<br>“Ялкау мәче” 114б.(11)<br>“Без шат балалар” уен (7) | Такмаклар 50б.(12)<br>“Бармак” уеннары 51б.(12)<br>“Чылбыр” 259б.(7) |
| Октябрь | *С/р уен* “Без шоферлар”, “Чәчтараш”<br>*Д/уен* “Туп нинди төстә?”(7)<br>“Бу нинди яшелчә?”, “Бу кем?”(7),”Бу нинди савыт-саба?”(7).<br>*Х/уен* “Флажокка кәдәр йогер”(10),”Очты-очты”(12),”Көн-төн”(12).<br>Бармак театры “Калач”<br>Курчак театры “Йокы бабай” | “Цирк”(5),<br>Әңгәмә:”Ягымлы сүзләр” 22б.(5)<br>Әкият” Төлке,куян һәм әтәч” 55б.(11) | Ситуация “Курчак Алсу нәрсә онытты?”4б.(3)<br>“Чәбәкәй” 16-17б.(4) |
| Ноябрь | *С/р уен* “Автобус”(8),”Әни-кыз”,”Ойле”,”Курчакны юындырабыз”<br>*Д/уен* “өс,баш,аяк киемнәре”(7),”Күрсәт әле үскәнем”(10),”Рәсемдә нәрсәләр ясалган?”(7),”Бу нәрсә?”(7).<br>*Х/уен* “Җил исә”, “Ак куян”(10) | “Кабартма”(Ак калач) уены (7).<br>“Әйе-юк” (7).<br>*Д/уен* “Мин күрсәтәм, сез әйтегез”(3). | Әңгәмә:”Исемең матур” 25б.(5)<br>“Бармак” уеннары (7).<br>“Күрсәт әле үскәнем” (7) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *С/р уен* “Аш бүлмәсе”,”Туган көн”.<br>*Д/уен* Җәяүлеләр”(8), ”Бу нинди транспорт?”(8),”Кушканны үтә(7),”Моны кая кияләр?”(6)<br>*Х/уен* “Көн-төн”(10), ”Чеби бнлән песи”(10), “Очты- | *Д/уен*”Серле сандык”(7)<br>Уен “Марат монда кил” 33б.(6)<br>*Х/уен* “Карусель”(11)<br>Әңгәмә “Уйнарга яратабыз”43б.(5). | *Д/уен* “Мин әйтәм син тап”(7).<br>*Х/уен*”Аюлар һәм балалар”(11)<br>“Бармак”уеннары. |
| Декабрь | очты”(10).<br>*Күләгә театры* “Кәҗә бәтиләре һәм бүре”<br>*Курчак театры* “Өч аю” | “Карусель”(11)<br>“Тынлык уены(11) | яратасың?” 9б.(3) |
| Январь | *С/р уен* “Супермаркет”Тәмле” ”ЮХИДИ”.<br>*Д/уен*“Бу кайчак була?”(7), ”Җылы-суык”(7),”Уенчык нинди?”34б.(6),”Тәрҗемәче”8б.(3)<br>*Х/уен* “Җил исә”,”Кем юк?”,”Кем тизрәк”,”Кошлар”.<br>*Бияләй театры* “Шалкан”. | Ситуация “Дустыңа шар бир”<br>“Чылбыр” 6б.(3) | “Бармак”уеннары.<br>Уен “Син кемне |
| Февраль | *С/р уен* “Курчакның туган көне”,”Курчакны юындырабыз”<br>*Д/уен* “Чыршы бизәү” 18б.(3),”Мин күрсәтәм сез әйтегез”(7),”Нинди?” 37б.(6)<br>*Х/уен* “Светофор” 27б.(11),”Үз төсеңне тап(10), “Песи һәм тычканнар”(10), “Маэмай”(10)<br>“Башак”әкияте буенча өстәл өсте театры.” Кәҗә бәтиләре һәм бүре” өстәл өсте театры. | Уен “Үзеңне макта”(3).<br>Җырлы биюле уен “Парлашып калу(13).<br>Уен “Киеменнән таны”(7). | “Гаилә чәчәге” уены 94б.(13).<br>“Бармаклар” уеннары. |
| Март | *С/р уен* “Шифаханә” “Машиналар төзекләндерү станциясе”.<br>*Д/уен*”Рәсемне ясап бетер” 14б. (3), “Автобусны ясап бетер”, “Төсне тап”,”Бу әйбер нигә кирәк?”(7), “Мин әйтәм, син тап”40б.(6)<br>*Х/уен* “Машина һәм чыпчыклар”, “Трамвай”(10),”Әбәкле”,”Энә, җеп, төен”(10),”Куык”(11).<br>*Өстәл театры* “Йомры икмәк” | Уен “Чәбәкәй”(4)<br>Уен”Эндәшмә(11)<br>Балаларны уенга җыю өчен күнегүләр”Уңган балалар”(11) | “Бармак”уеннары(4).<br>*Д/уен* “Бу кем?”,“Кем юк?” 41б.(6) |
| | *С/р уен* “Кибет”,”Уенчыклар кибетендә”.<br>*Д/уен* “Тамчы там” 29б.(3),”Әйе юк”(7).Табышмаклар, кирәкле | Уен “Иптәшеңне сыйла”,”Ак калач” уены.<br>Җырлы биюле уен “Минем күлмәгем матур” 20б.(3) | Табышмаклар.<br>*Д/уен* “Нишли?”. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Апрель | сүзен әйт 20б.(3),"Кия сала"(7).<br>*Х/уен* "Аю-бүре","Ал кирәк-гөл кирәк(10),"Куышлы", "Үз төсеңне үзләп тап"<br>*Сәхнәл.уен* "Чыпчыклар һәм песи". | | |
| Май | *С/р уен* "Әнигә булышабыз","Кунак көтәбез", "Савыт-саба кибете"<br>*Д/уен* "Күбрәк-әзрәк"(7), "Охшаганмы -юкмы?"(7),"Шулай буламы-юкмы?"(11), Дөрес светофорны эзләп тап" (8), "Үз парыңны тап"(7).<br>*Х/уен* "Тигез юл буйлап"," Мәче Һәм тычканнар", Үз төсеңне тап", "Трамвай","Инеш аша үтәбез"(10). | Уен "Курчак өчен бүләкләр сатып алу" 89б.(13), "Ак калач" 90б.(13) | "Бармак" уеннары (7), "Серле тартма" (7), "Гаилә чәчәге" уены 94б.(13). |

**Гади математик күзаллау формалаштыру**
**Аңлатма язуы.**

Төркемнең эшчәнлеге төп гомумбелем бирү программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә:
- «Об образовании» Федераль законы, 29.12.2012 ел № 273.
- РФ белем бирү министрлыгының № 1155 17 октябрь 2013 ел «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования" приказы.
-"Типовое положение о дошкольном образовательном учреждении» , РФ җитәкчелеге карары белән расланган.
-Закон РТ №44 от 28.07.2004 г. «О государственных языках РТ и других языках в РТ»
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының хаты: "Об эффективности внедрении новых УМК" № 968/13 20.01.2013 ел.
-ТР Министрлар кабинеты 30.12.2010 елгы № 1174 «Об утверждении Стратегии развития образования в Республике Татарстан на 2010-2015 гг. "Киләчәк" программасы;
- "Санитарно-эпидемиологическаие требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций", СанПиН 2.4.1.3049 -13 РФ нең дәүләтенең баш врачы карары белән расланган 15.05.2013 № 26;
-сетка занятии утвержденным приказом № от .08.2019г

- Төркемдәге предметларның уртак билгеләрен күрә белү күнекмәләрен үстерү (барысы да кызыл төстә, барысы да зур һ.б.).Бер төрле предметлардан төркемнәр төзергә һәм шулардай аерым предметларны аерып алырга: күп, бер, берәмләп төшенчәләрен белергә; әйләнә-тирәдән бер һәм күп предметларны табарга; ничә? соравын аңларга; җавап биргәндә күп,бер,берәүдәюксүзләре файдаланырга өйрәтү.
- Предметларны юанлыгы, киңлеге һәм биеклеге буенча чагыштыр ганда, аларны берсе өстенә икенсесен кую, һәм янәшә кую ысулларын файдаланырга өйрәтү, эш нәтиҗәләрен сүзләр белән әйтә белергә күнектерү (озын-кыска- озынлыклары тигез, киң, тар, бердәй киңлектә).
- Түгәрәк, квадрат, өчпочмакны танып белергә; күреп, капшап карап фигураларның формасын билгеләргә өйрәтү.
- Балаларны уң һәм сул кулларын күрсәтә, үзенә карата пространство юнәлешләрен билгеләргә өйрәтү.
- Тәүлекнең капма-каршы өлешләрендә ориентлашырга өйрәтү:иртә-кич, көн-төн.

Ел ахырына үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр:

Төсе, формасы, зурлыгы буенча предметларны төркемләү (барлык кызыл, барлык зур, барлык түгәрәк предметларны сайлап алу).

Өлкәннәр ярдәмендә аерым предметларны бер төркемгә җыеп берләштерә, төркемнән бер предметны аерып ала белү.

Әйләнә-тирәдәге бер һәм күп санлы бердәй предметларны таба белү.

Бер предметны икенчесенең өстенә, астына, янына кую юлы белән зурлыклары төрле булган ике предметны чагыштыру: кайсы предметның озынрак –кыскарак, киңрәк –таррак, биегрәк –тәбәнәгрәк булуын күрсәтү.

Түгәрәк, квадрат, өчпочмак, почмак, почмаклы һәм түгәрәк формалы предметларны танып әйтү белү.

Түбәндәге сүзләрнең мәгънәләрен аңлау: өстә-аста, алда-артта, сулда-уңда, өстендә-астында, өске-аскы (сызык).

Программа:

"Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы" (дүртенче басма, 2006 ел).

Методик ярдәмлекләр:

Игровая деятельность на занятиях по математике (младшая группа). П.Г.Федосеева, 2005г.
Математика для детей 3-4 лет. Е.В.Колесникова, 2005г.
"Чудо-обучайка" для детей 3-6 лет. Е.Бортникова, 2006г.
"Игралочка" математика для детей 3-4 лет. Л.Г.Петерсон, 2008г.
Занятие елга- 36; атнага 1 тапкыр уза; занятие вакыты - 15 минут ;елга 2 тапкыр диагностика уздырыла.

| № | Максат | Демонстрацион материал | Тарату материалы | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Төсенә һәм зурлыгына бәйсез рәвештә шар һәм кубикны танып әйтә алуларына ирешү. Балаларда игътибарлылык тәрбиләү. | Фланелеграф,кызыл ,зәңгәр кубиклар | Вак уенчыклар, | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Зур һәм кечкенә төшенчәсе кулланып предметларны аерырга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның сөйләм телләрен камилләштерү. Игътибарлыкларын үстерү. | Уенчыклар, рәсемнәр | Кубиклар | |
| 3 | Зур һәм кечкенә төшенчәсе кулланып предметларны аерырга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның сөйләм телләрен камилләштерү. Игътибарлыкларын үстерү. | Уенчыклар, рәсемнәр | Кубиклар | |
| 4 | Төсенә һәм зурлыгына бәйсез рәвештә шар һәм кубикны танып әйтә алуларына ирешү. Балаларда игътибарлылык тәрбияләү. | Фланелеграф,<br><br>кубиклар, шар | вак уенчыклар | |
| 5 | Бер, күп, әз сүзләрен кулланып предметларның күләмен билгеләү. Зур һәм кечкенә төшенчәсе кулланып предметларны аерырга өйрәтүне дәвам итү. | Курчак, аумас курчаклар | Карточкалар, уенчыклар, геометрик фигуралар. | |
| 6 | Бер, күп, әз сүзләрен кулланып предметларның күләмен билгеләү. Предметларны төркемләргә, шул төркемнән бер предметны аерып ала алуларына ирешү, балаларның игътибарлыкларын, күзәтүчәнлекләрен арттыру. | Курчак, бер зурлыктагы туплар | Уенчыклар, туплар | |
| 7 | Өскә, аска, алга, артка төшенчәләрен өйрәнү. Аслы, өсле урнашкан ике тасмага предмет куя белү. Бер һәм күпне күрә әйтә белү. “һәм” теркәгечен куллану. | дидактик уен | Вак уенчыклар, баскыч | |
| 8 | Геометрик фигуралар- түгәрәк белән танышу, төрле размерда булуларын белү. Бер һәм күпне ныгыту. Җәенке җөмлә белән әйтә белү. | Геометрик фигуралар | Геометрик фигуралар,<br><br>зур, кечкенә түгәрәкләр | |
| 9 | Әзерләнгән предметлардан бер һәм күпне табарга өйрәнү. Түгәрәк һәм квадратны капшап һәм күреп тану. | Баскыч | Предметлар. уенчыклар түгәрәк, квадрат. | |
| 10 | Уң һәм сул кулны аерырга өйрәнү. Бер һәм күпне табуны ныгыту. Түгәрәк һәм квадратны капшап һәм күреп тану. | Панно | Карточкалар, геометрик фигуралар | |
| 11 | Бер һәм күпне табуны ныгыту. Түгәрәкне квадратны танып әйтү. Күреп һәм капшап тану үзлекләренә өйрәтү. 1саны белән танышуны дәвам итү. Уң һәм сул кулны аера белү. | Серле капчык. | Түгәрәк һәм квадратлар | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Ике предметны озынлыгы буенча чагыштырырга өйрәнү. Озынрак, кыскарак сүзләрен куллану. Өстә, аста, унда, сулда төшенчәләрен ныгыту | Өй моделе, ике уенчык ат. | Ике тасма, | |
| 13 | Берсе өстенә икенчесен кую юлы белән озынлыкны чагыштыру. (Озынрак, кыскарак) Әйтелгән санда шул тасмаларга предмет кую. Уң кул белән сулдан уңга тезү. | Ике аю | Вак уенчык лар, ике тасма. | |
| 14 | Өстенә кую, янына кую юлы белән предмет- ларны чагыштыру. Ничә, шулкадәр, бертигез төшенчәләрен өйрәнү. | Панно | Карточкалар, 2 төрле предметлар | |
| 15 | Карточкада ничә предмет шулкадәр куярга өйрәтү. Төрле төстәге, зурлыктагы түгәрәк, квадрат, өчпочмакны аера белү. Уеннар аша логик фикерләү сәләтләрен үстерү. | Төзү материаллары, рәсемнәр. | Карточкалар, геометрик фигуралар | |
| 16 | Предметларны киңлек буенча чагыштырырга өйрәнү. Озынлык буенча чагыштыруны ныгыту. 2 саны белән танышу. | Түгәрәк, өчпочмак, квадрат модельләре. | Киңлеге төрле ике тасма | |
| 17 | Киңрәк, таррак, бертигез киңлектә төшенчәләрен өйрәнү. Предметларны киңлек буенча чагыштырырга өйрәнүне дәвам итү. Өстә, аста сүзләрен куллану. | Маскалар, шнурлар | Өләшү өчен ике тасма | |
| 18 | Биеклеге төрле булган предметларны чагыш тырырга өйрәнү.(Янәшә кую алымы белән) Биегрәк-тәбәнәгрәк, биек-тәбәнәк сүзләрен куллану | Ике курчак,чашка, стакан | Өләшү материалы. | |
| 19 | Предметларны биеклек буенча чагыштыру, ике бертигез биеклектәге предметларны таба белергә өйрәтү. Озынлык, киңлек буенча чагыштыруны ныгыту. | Биек, тәбәнәк уенчыклар | Өләшү өчен вак уенчаклар | |
| 20 | Биегрәк, тәбәнәгрәк, бертигез биеклектә сүзләрен кулланырга өйрәтү. Бер һәм күп төшенчәләрен ныгыту. | Курчаклар, кровать | предметлар | |
| 21 | Берсе өстенә икенчесен кую юлы белән күп предметларны чагыштырырга өйрәнү. Күбрәк, азрак, ничә, шулкадәр сүзләрен куллану. Уң кул белән сулдан уңга тезү. | Панно | Карточкалар | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 22 | Өстенә кую, янына кую алымы белән предметларны чагыштырырга өйрәтү. Ничә, шулкадәр, бертигез төшенчәләрен ныгыту. | Панно, гөмбәләр | Ике төрле предметлар, икешәр карточка | |
| 23 | Карточкада ничә предмет шулкадәр куярга өйрәтү. Ничә, шулкадәр, бертигез төшенчәләрен аңлау. Төрле төстәге, зурлыктагы геометрик фигуралар танып әйтә белү. | Геометрик фигуралар | Карточкалар, геометрик фигуралар | |
| 24 | Карточкадагы предмет янына рәсемнәр куя белү.Тәгәл астына кую. Ничә, шулкадәр, бертигез төшенчәләрен куллану. Киңлек буенча чагыштыруны ныгыту. | Панно, ике аю, шарф | Рәсемнәр | |
| 25 | Ике предметны юанлык буенча чагыштырыр га өйрәнү. Юанрак, нечкәрәк төшенчәләрен әйтә белү. Берсе янына икенчесен тәгәл куя белүне ныгыту. Ничә, шулкадәр-белү. | Ике банка, ике таякчык | Өләшү өчен карточкалар, рәсемнәр | |
| 26 | Карточкадагы геометрик фигураларга модель ләрен куя белү. Юанлык буенча ике предмет ны чагыштыруны ныгыту. Юанрак, нечкәрәк сүзләрен куллана белү. | Төзү материаллары | Түгәрәк, өчпочмак, квадратлар | |
| 27 | Тигез һәм тигез булмаган предмет төркемнәрен чагыштыру, сүз белән әйтү. Күбрәк, азрак, бертигез, озынлык, биеклек, киңлек буенча чагыштыруны дәвам итү. Өч саны белән танышу | Панно | Карточкалар, геометрик фигуралар | |
| 28 | Берсе өстенә икенчесен кую (приложение) алы мы белән ике предметны зурлык буенча чагыштыру.Зур, кечкенә сүзләрен куллана белү. | Түгәрәк, өчпочмак, квадратлар | Карточкалар, түгәрәк, өчпочмак, квадратлар | |
| 29 | Ничә уенчык шулкадәр хәрәкәт ясарга өйрәтү. Ике төркем предметларны берсе өстенә берсен куеп, берсе янына икенчесен куеп чагыштырырга өйрәнү. | Өч матрешка, куян, аю | Карточкалар | |
| 30 | 1-3 эчендә тавышны саный белү. Ничә тавыш, шулкадәр предмет куя белү. Янына кую алымы белән предметларны чагыштыру. | Чүкеч, ширма | Уенчыклар | |
| 31 | Тигез, тигез булмаган предмет төркемнәрен чагыштыру. Сүз белән әйтә белү, күбрәк, азрак, бертигез. Уеннар аша логик фикерләү сәләтләрен үстерү. | Өй силуэты | геометрик фигуралар, | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 32 | Ничә тавыш ишетәсе шулкадәр  предмет ясалган  карточка табарга өйрәтү. Озынлык, биеклек, киңлек буенча чагыштыруны ныгыту. | Чүкеч, ширма | Төрле зурлыктагы уенчыклар | |
| 33 | 4 саны белән танышу. Кайсы төркемдә предметлар күп, кайсысында аз икәнен ачыкларга өйрәтү.  Санауны, геометрик фигураларны аеруны ныгыту. | Баскыч, ике төркем уенчык | Геометрик фигуралар | |
| 34 | Ике төркем предметларны чагыштыру. Биш эчендә предметларны санарга өйрәтүне дәвам итү. Күбрәк, азрак бертигез төшенчәләрен куллану. Уеннар аша игътибар үстерү. | Панно, уенчык рәсемнәре | Вак уенчыклар | |
| 35 | Уң һәм сул кулны пространстводагы юнәлешләрен (уңда, сулда, алда, артта, өстә, аста) аера белергә өйрәтү. Предметларны тануны, (түгәрәк, өчпочмак, квадратлар) ныгыту | Бүлмәдәге җиһазлар | геометрик фигуралар | |
| 36 | Тәүлекнең бүленеше турында күзаллау булды ру (иртә-кич, көн-төн) Уң һәм сул кулны ныгыту. Сан ягыннан тигез төркемне чагыштыру. Кимрәк санлы төркемгә бер  предмет өстәп яисә алып тигезләп урнаштырырга өйрәтүне ныгыту. | Рәсемнәр, уенчыклар | геометрик фигуралар | |

# Сөйләм үсеше

Аңлатма язуы.

План балалар бакчасында  икенче кече яшьтәге балалар белән эшләү өчен ФГОС Һәм Р. К. Шаехованың  “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”,  Ф.В  Хәзрәтованың “Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик кулланмасы нигезендә  балаларны ана телен дә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү , тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру максатыннан чыгып төзелде. Методик әсбап танып белү, сөйләм үстерү, матур әдәбият белән таныштыру кебек белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар — «Безнең балалар бакчасы», «Көз», «Мин — дөньяның бер кешесе», «Минем әйләнә-тирәм», «Кыш», «Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр», «Халык иҗаты»,«Яз», «Җәй».  Өченче

яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычларын хәл итә. Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү мәсьәләләрен чишкәндә, өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе — бармак уеннары. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары" Ф.В Хәзрәтованың "Туган телдә сөйләшәбез" укыту –методик кулланмасы нигезендә төзелде. Беренче кече яшьтәге төркем балаларының сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләмен үстерү эшчәнлеген оештырганда ,әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына.

Бу укыту-методик комплектында ФГОС күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

- **"Танып белү" белем бирү** өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләрдә экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында балаларның белемнәр тирәнәйтүне максат итеп куя.

- **"Аралашу" белем бирү** өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара-каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра.

- **"Матур әдәбият" белем бирү** өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләрбелән танышуны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.

Укыту-методик комплектында тупланган материал шулай ук балаларның сөйләмен үстерү, тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында рәсем ясау, әвәләү, конструкцияләү, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә кулланыла һәм ныгытыла.

Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә, балалар индивидуаль эшне оештыру максатыннан мониторинг үткәрелә, аның нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

| Вакыты | Тема | Бурычлар | Эш төрләре | Интегральләштерү | Форма | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Җәй белән саубуллашу | 1) җәй турында күзаллауларга нигез салу, тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен; күз алдына китерә, хыяллана белүләрен; вак моториканы, рәсем ясау күнекмәсен, иҗади сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү | Уен ситуациясе<br>“Табышмак әйтү”<br>Сөйләм үстерү<br>Шигырь өйрәнү | нәфис-нәфасәти<br>үсеш өлкәсе | группа | А 4 форматындагы ак кәгазь битләре, (аларга диаметры 8-9 см булган сары түгәрәкләр ясалган), һәр бала өчен сары, тәрбияче өчен зәңгәр, кызыл төстәге фломастерлар, «Иртәнге нур» (С. Садыйкова көе, З. Вәли сүз.) җырының аудиоязмасы |
| | “Ә” авазын | 1) «ә» сузык авазын дөрес итеп, кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү. «Ә» авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүне ныгыту;<br>2) сорауларга җавап бирергә теләк уяту<br>3) сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәр-бияләү | Уен ситуациясе<br>“Күңелле тел”<br>“Курчак җырлый”<br>“Табиб янында” | хезмәт | группа | курчак, караватъ, фланелеграф; сөт эчеп торган песи, ползунки кигән курчак рәсемнәре. Аерым өстәлгә уенчыклар куелган (аю, төлке, курчак, әтәч һ.б.). |
| | З.Гөмәрованың “Ул шуңа кечкенә” дигән шигырен уку | 1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү; аерым сүзләрне, фразаларны тәр-бияче артыннан дөрес итеп кабатлауларына ирешү; сүзлекләрен активлаштыру;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерләрен, хәрәкәт активлыкларын үстерү;<br>3) әсәргә карата кызыксыну уяту, сәламәт<br>яшәү теләге тәрбияләү. | Шигырьне уку<br>Әңгәмә оештыру<br>Хәрәкәтле уен | нәфис-нәфисәти үсеш | группа | курчак, «Курчак» җырының аудиоязмасы<br>(М.Бикбова сүзләре һәм көе). |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бакчада алмалар өлгерде | 1) балаларның көз, табигатьтәге көзге үзгәрешләр,җиләкҗимешләр(алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү; 3) күмәк эшләүгә тарту, сорауларга җавап бирү теләге тәр-бияләү. | Яңа материал бирү<br>Уен ситуациясе<br>«Серле капчык»<br>Уен ситуациясе<br>“Уен ситуациясе<br>«Зур, баллы, татлы алма» | | группа | «Серле капчык», алма («серле капчыкка» салына); чыршы, каен, алмагач рәсемнәре; магнитлы такта, алмагач макеты, төрле төстәге зур һәм кечкенә алмалар, ковровраф, зур һәм кечкенә ике чиләк |
| | Э.мөэминова ның “Үз телендә сөйләшә" шиг уку | 1) балаларны Э. Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» дигән шигыре белән таныштыру; аерым сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлап, сөйләмдә активлаштыру;<br>2) аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге тәрбияләү. | Шигырьне уку<br>Әңгәмә оештыру<br>“Туган тел” җырына кушылып җырлау | нәфис-нәфисәт и үсеш | группа | «Туган тел» җырының аудиоязмасы ( Г. Тукай<br>сүзләре, халык көе). |
| | Йомшаккай әзерләгән сюрприз | 1) агачтан ясалган уенчык-ларны карау барышында агач материалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү;<br>2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлекбайлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш, уеннан соң уенчыкларны урынына кую гадәте тәрбияләү. | Уен ситуациясе<br>“Серле тартма”<br>Уен ситуациясе<br>“Без матрешкалар” җырлау | | группа | тартма, уенчык песи (Йомшаккай), карау өчен<br>пирамида, зур матрешка һәм һәр балага җитәрлек матрешкалар |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Алтын көз | балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;<br><br>2) балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;<br><br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү. | Ел фасылы турында аңлату. Рәсем буенча эш.<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“Төсләре буенча төрле”<br><br>“Күп,аз” | | группа | көз рәсеме төшерелгән рәсем; кызыл һәм сары<br><br>тасмалар бәйләнгән ике кәрзин; һәр балага кызыл һәм сары<br><br>яфракларның контурлы сурәтләре, берәр ал |
| | “Туп” | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; сорауларга җавап бирүгә күнектерү;<br><br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, интонацияле сөйләмен үстерү;<br><br>3) балаларда кечкенәләр турында кайгыртучанлык хисе тәрбияләү; бергә шөгыльләнергә теләк уяту | Шигырьне уку<br><br>Әңгәмә оештыру<br><br>Хәрәкәтле уен | физик үсеш | группа | курчак, бала санынча кәрзингә салынган кечкенә<br><br>туплар, савытлар белән су |
| | Мультфильм карау | 1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.<br><br>2. Уенчыклар лексикасын сөйләмдә активлаштыру<br><br>3. Игътибарлылык, дуслык тәрбияләү. Утырып торучанлык булдыру | | | группа | УМК дан анимацион сюжетлар |
| | манара | 1) балаларны төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү.<br><br>2) предметның төсен, фор-масын, зурлыгын атый бе-лүләренә ирешү; | Уен ситуациясе<br><br>“Манара төзү”<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“ зур,кечкенә” | нәфис-нәфисәти үсеш | группа | Уенчык песи, тартма белән төрле зурлыктагы (зур, кечерәк, кечкенә), төрле төстәге (кызыл, яшел, зәңгәр) шакмаклар. Н. Гайсин сүзләре, Н. Зарипова музыкасына «Балалар |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 3) бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | Җыр өйрәнү | | | бакчасында» җырының аудиоязмасы |
| | “Баш бармак” шигри әсәрен уку | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеге аша бармак атамаларын истә калдыру, бармак уеннары өйрәнү;<br><br>2) балаларның аңга<br><br>алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, бармакларының хәрә-кәтчәнлеген үстерү;<br><br>3) халык авыз иҗатына хөрмәт тәрбияләү. | шигъри әсәрнең эчтәлеге аша бармак<br><br>атамаларын истә калдыру, бармак уеннары өйрәнү | | группа | |
| | “Аю белән Бабай”<br><br>әкиятен уку | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; үсемлекләр турындагы белемнәрен киңәйтү; сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;<br><br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, кулның вак моторикасын үстерү;<br><br>3) халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү | Сорау лар биреп,<br><br>Аю белән бабай сүрәтләрен фланелеграфта күрсәтә бару | | группа | фланелеграф (ковроград); аю, бабай, шалкан, бодайның контурлы сурәтләре; поднос; капчыкка салынган бодай бөртекләре, балалар санынча аю битлекләре |
| | Куян үстергән кишер һәм помидор | 1) балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;<br><br>2) балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;<br><br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү | Уен ситуациясе<br><br>“Исәнләшү”<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“Кунак килә”<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“Куян үстергән кишер һәм помидор” | хезмәт | группа | уенчык куян, балалар санынча кишер, помидор,<br><br>«серлетартма |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Ш.Маннурның “Яратам” шиг яттан өйрәнү | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; сүзлекне баету һәм активлыштыру; гаилә сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;<br><br>2) шигъри әсәрне яттан сөйләргә теләк уяту; аңга алуларын, хәтерне, игътибарны үстерү;<br><br>3) гаиләгә карата хөрмәт, туганлык хисләре тәрбияләү | балаларга гаилә сурәтләнгән рәсем күрсәтү<br><br>«Гаилә»<br><br>сюжетлы-рольле уен | | группа | |
| | КУЯН ҮСТЕРГӘН КЫЯР ҺӘМ ШАЛКАН | 1) балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, шалкан) турындагы белемнәрен ныгыту;<br><br>2) яшелчәләрне (кыяр, шалкан) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белергә өйрәтүне дәвам итү; игътибарларын, аңга алуларын; диалогик сөйләм, сенсорик сәләтләрен үстерү;<br><br>3) сорауларга җавап бирү теләге тудыру; табигать белән кызыксыну тәрбияләү | Уен ситуациясе<br><br>“Куяннан серле тартма”<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“Бабай үстергән шалкан”<br><br>Күмәк эш “Әвәләү” | | группа | уенчык куян, балалар санынча кыяр, шалкан;<br><br>«серле тартма» |
| | Ә.Ерикәйнең “Көз” шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга, аны истә калдырырга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; шигырьдәге килде, саргайды, шиңде, сибелде фигыльләре хисабына сүзлекне баету;<br><br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарларын үстерү;<br><br>3) көзге матурлыкка соклану хисе, күзәтүчәнлек тәрбияләү. | Шигырьне уку<br><br>Әңгәмә оештыру<br><br>“Яфрак бәйрәме” җырын тыңлау | нәфис-нәфисәти үсеш | группа | көзге урман сурәтләнгән рәсем, «Яфрак бәйрәме»<br><br>җырының аудиоязмасы (Р. Еникеева көе, Л. Лерон сүзләре). |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сары,кызыл яфраклар | 1) балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълү-мат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту;<br><br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү; көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү;<br><br>3) балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү. | Уен ситуациясе<br><br>“Серлеконверт”<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“Келәм ясау” | нәфис-нәфисәт и үсеш өлкәсе | группа | көзге һәм кышкы пейзажлар сурәтләнгән<br><br>рәсемнәр, яшел төскә буялган ватман (келәм); һәр балага<br><br>җитәрлек сары яки кызыл төстәге яфраклар, пумалалар, җилем,<br><br>салфеткалар; «Яфрак бәйрәме» (Р.Еникеева көе, Л.Лерон сүз.)<br><br>җырының аудиоязмасы. |
| | М.Фәйзуллин анын<br><br>“Көзге яңгыр” шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, уен барышында чикләнгән мәйданда йөгерергә күнектерү;<br><br>2) аңга алуларын, игътибарларын үстерү; тәрбияче сигналы буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү;<br><br>3) шигъри әсәр белән кызыксыну, уен ярдәмендә тыңлаучанлык тәрбияләү. | шигырьне укып коврографта шигырьдә сурәтләнгән<br><br>күренешләрне күрсәтә бару: яңгыр ява, зонтик тоткан бала апасы белән бара | | группа | коврограф. Кояш, болыт, яңгыр, апа, сеңелнең<br><br>контурлы сурәтләре. Зур зонт. |
| | “Безнең кунаклар” мулт карау | 1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.<br><br>2.Уенчыклар лексикасын сөйләмдә активлаштыру<br><br>3. Игътибарлылык,дуслык тәрбияләү.Утырып торучанлык булдыру | | | күмәк | УМК дан анимацион сюжетлар |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин һәм минем гаиләм | 1) балаларның гаилә һәм гаи-лә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; исемнәрне сан, тартым белән төрләндерүгә (әни-әниләр, әни-әнием) күнектерү;<br><br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br><br>3) олылар белән ирекле аралашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү | Уен ситуациясе<br><br>“кунак килә”<br><br>Уен ситуациясе<br><br>“Чәй өстәле хәзерлибез”<br><br>“Чәй эчәбез” | нәфис-нәфисәт и үсеш | группа | гаилә (әти, әни, бабай, әби, кыз, малай)<br><br>сурәтләнгән рәсем; әти, әни, бабай, әби, кыз сурәтләнгән<br><br>рәсемнәр; күп әниләр, әтиләр, әбиләр, бабайлар, кызлар, малай-<br><br>лар сурәтләнгән рәсемнәр, малай курчак. |
| | “Кем нәрсә ярата?” дигән татар халык әкиятен сөйләү | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; балаларның йорт кошлары һәм хайваннары турындагы күзаллауларына төгәллек кертү; аваз ияртемнәрен ачык һәм дөрес әйтергә<br><br>күнектерү;<br><br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, образлы фикерләүләрен, ишетү сәләтен үстерү;<br><br>3) кошларга, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | | | группа | песи, эт, әтәч, кәҗә уенчыклары, «Безнең дусла-<br><br>рыбыз» җырының аудиоязмасы (М. Хөсәен сүзләре, А. Ключарев<br><br>музыкасы) |
| | Алсуның яңа өе | 1) балаларны йорт җиһаз-лары белән таныштыру, бил геләнешләре буенча гомумиләштерергә өйрәтү; бирелгән сорауны аңлау һәм җавап бирүләренә ирешү;<br><br>2) җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен, аларның нинди материалдан эшләнгәнен ачыклауларына ирешү; артында, янында, өстендә кебек сүзләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү;<br><br>3) йорт җиһазларына карата сакчыл караш тәрбияләү. | Уен ситуациясе<br><br>“Алсуның яңа өенә җиһазлар алабыз”<br><br>“Алсу кайда” | | группа | курчак, аның бүлмәсенең макеты, уенчык йорт<br><br>җиһазлары (өстәл, урындык, табуретка, диван, кәнәфи, сервант), машина |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | “Баш бармак” шигъри әсәрен уку | 1) балаларның яңа шигырьне эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, сорауларга төгәл итеп җавап бирергә күнектерү;<br>2) аңга алуларын, игъти-<br>барын, фикерләүләрен, хәрәкәтләре төгәллегенен үстерү;<br>3) балаларда пөхтә һәм чиста йөрү теләге тәрбияләү. | шигъри әсәрнең эчтәлеге аша бармак<br>атамаларын истә калдыру, бармак уеннары өйрәнү | | группа | |
| | Кунак каршылыйбыз | 1) савыт-сабаның аерым предметлары, аларның ку-лланылышы турында беле-мнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; әңгәмәгә тарту;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү;<br>3) балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә бу лышу теләге уяту; савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү. | Уен ситуациясе<br>“Курчак белән танышу”<br>“Өстәл әзерлибез”<br>“Табынга куелачак предметларны карау,өйрәнү” | | группа | кыз һәм малай курчаклар, чәй өстәле, ашъяулык,<br>тартмада савыт-сабалар: чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек, чәй кашыклары, сай тәлинкәләр, шикәр савыты, чәй савыты, конфет<br>савыты, салфетка савыты; чәй, конфетлар, салфеткалар |
| | Уенчык песи баласы турында сөйләү | 1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уен-чыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчыктурында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аң га алуларын, күзәтүчәнлеген, сүз-лек байлыгын үстерү;<br>3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту; йорт хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. | Уен ситуациясе<br>“Песи турында сөйләү”<br>“Ак, кара песине тап” | | группа | уенчык ак һәм кара песи балалары, уен өчен<br>күңелле көй аудиоязмасы. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | мониторинг | | | | һәр бала белән аерым | |
| | Ә.Бикчәнтәев аның “Бәтиләр”уку | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү; сорауларга тулы җаваплар бирергә, аваз ияртемнәрен дөрес кабатларга өйрәтү;<br><br>2) балаларның аңга алуларын, сүзлек байлыгын, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;<br><br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык хисе тудыру. | балаларга фермадагы бәтиләр сурәтләнгән иллюстрация күрсәтү,<br><br>шигырьне уку,кушылып җырлау | нәфис-нәфисәт и үсеш | группа | уенчык бәрән яки бәрән рәсеме; йон, йон-<br><br>нан бәйләнгән бияләй, шәл, оекбаш, киез итекләр; «Бәтиләр»<br><br>җырының (Ә. Бакиров музыкасы, Ә. Бикчәнтәева сүзләре) ау-<br><br>диоязмасы. |
| | Минем йортым, минем районым | 1) балаларны туган район, аның исеме , районда ясала торган сөлге, кирпеч Һ.Б белән таныштыру,<br><br>2) аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү<br><br>3) туган район ,аның эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү | Рәсем буенча эш<br><br>Уен ситуациясе<br><br>«Әтием, әнием һөнәре” | хезмәт | группа | туган район ,аның эшчеләре, аларның хезмәтетурынла презентация |
| | “Әлли-бәлли итәргә...” бишек җырын уку | 1) бишек җырының эчтәлеген, тәрбияче сөйләмен аңлауларына ирешү; сөйләмдә тирбәтергә фигылен куллана белергә өйрәтү;<br><br>2) аңга алуларын, игътибарны, конкрет-образлы фикерләүләрен үстерү;<br><br>3) сөйләм этикетының гади кагыйдәсен (тәмле йокы теләү) тормышта куллану теләге уяту; бишек җырлары | Шигырьне уку<br><br>Әңгәмә оештыру<br><br>“Бишек җырын” җырын тыңлау | | группа | елый торган курчак, бишек |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | белән кызыксыну, аларны уен вакытларында җырларга омтылыш тәрбияләү. | | | | |
| | Н.Каштанның “Безнең сыер” шигырен уку. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; кайбер сүзләрне (мөгери, китер, йөгер) үзләштерүләренә ирешү, [у] авазы кергән аваз ияртемнәрен әйтергә күнектерү;<br><br>2) балаларның игътибарын, аңга алула рын үстерү;<br><br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. | Шигырьне уку<br><br>Әңгәмә оештыру | | группа | сыер рәсеме. |
| | Серле шкатулка | 1) балаларны уенчыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк тәрбияләү;<br><br>2) балаларны уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләргә өйрәтү, диалогик сөйләмнәрен үстерү, сорауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә бе рләштерергә өйрәтә башлау;<br><br>3) уенчыкларга сак караш тәрбияләү; балаларда яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру. | Уен ситуациясе<br><br>“Серле шкатулка” | нәфис-нәфисәт и үсеш өлкәсе | группа | шкатулка; төрле төстәге, төрле зурлыктагы, төрле формадагы уенчыклар, балалар санынча кәгазьдән<br><br>киселгән кар бөртекләре, савытка салынган кар |
